# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлегенең Тойма торак пунктында гражданнар җыены нәтиәләре турында

06.04.2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2024 елның 26 мартындагы 6 номерлы 2023 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Тойма авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 27 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Тойма авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында карары белән 2024 елның 6 апрелендә узган гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде. Җыенда 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Тойма авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Тойма авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсенә сез ризамы” дигән сорау каралды һәм чаралар түбәндәгечә бәян ителде:

«1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (вак таш сатып алу, Вахитов урамы буенча тигезләү, юлларны кардан чистарту)?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмәгә ярашлы: сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 77 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны –54 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«риза» - гражданнар җыенының 54 катнашучысы тавыш бирә;

«каршы» - җыенның 0 катнашучысы тавыш бирә.

Бу нигездә, гражданнар җыенын:

1. Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Тойма торак пунктында гражданнар җыены узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип таныргa

2. 2023 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Тойма авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 27 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Тойма авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү

турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсенә сез ризамы" дигән сорау каралган һәм чараларны түбәндәгечә бәян итеп кабул ителгән дип санарга.
«1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (вак таш сатып алу, Вахитов урамы буенча тигезләү, юлларны кардан чистарту)?».

3. Әлеге карарны карар кабулителгән көннән 10 көн эчендә мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru "Енабердино авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга

4. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге башлыгы _______________ Е.Ю.Скворцова
(имза) (имзаның аңлатмасы)